**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru


---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» май 2020 ел** **№ 151**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 июнендәге 126 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турындагы Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында (2009 елның 25 мартындагы 70 номерлы карар редакциясендә)

2020 елның 18 мартындагы 53-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны исәпкә алып, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 июнендә кабул ителгән 126 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турындагы нигезләмә турында» карарына (2009 елның 25 мартындагы 70 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.15 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.15. Наркотик һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны иртә ачыклау максатыннан укучыларга социаль-психологик тест үткәрүне оештыра. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларның социаль-психологик тестын оештыру тәртибе гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу буенча федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контроьдә тотуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов